**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.12.2019 № 1090

Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчаларын) гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм аларны күчерү» 2019 елның 14 мартындагы 241 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 26 июлендәге 963 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчалары) гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм аларны күчерү" муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2019 елның 14 мартындагы 241 номерлы карары белән расланган

муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.9 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) оешмага кабул итү өлешендә:

- әлеге статьяның 5 һәм 6 өлешләрендә һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 88 статьясында каралган очраклардан тыш, анда буш урыннар булмау.»;

1.2 пунктның унөченче абзацында «наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнары " сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.В. Сорковнинага йөкләргә.

Җитәкче Р. М. Заһидуллин